| | |
|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА<br>И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ<br>ҺӘМ АЗЫК- ТӨЛЕК<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

21.02.2018 г .Казань № 37/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләү коррупциячел хәтәрлекләргә бәйле булган, биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең), балигъ булмаган баласының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләү коррупциячел хәтәрлекләргә бәйле булган, биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең), балигъ булмаган баласының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар таарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүчеләр тарафыннан керемнәре, **чыгымнары,** мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы Указы нигезендә **боерам:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләү коррупциячел хәтәрлекләргә бәйле булган, биләгәндә дәүләт граждан

хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең), балигъ булмаган баласының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле вазыйфалары исемлеген (алга таба – Исемлек) расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Кадрлар бүлеге башлыгы Г.Х.Кадыйровага:

әлеге боерыкны Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә;

Исемлеккә кертелгән вазыйфаларны биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләренә аларны вазыйфаларыннан азат иткәндә «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы чикләүләр, бурычлар һәм җаваплылык турындагы нигезләмәләрен аңлатырга.

3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләү коррупциячел хәтәрлекләргә бәйле булган, биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең), балигъ булмаган баласының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 173/2-пр номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен үзем тикшереп торам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
2018 елның _21__февралендә_
___37/2-пр__номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең биләү коррупциячел хәтәрлекләргә бәйле булган, биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үз хатынының (иренең), балигъ булмаган баласының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле вазыйфалары

ИСЕМЛЕГЕ

ячсмитҗбю.эңдлорпавыфйөукукенгннгшәшә

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

1.1. Министрның беренче урынбасары;

1.2. Министр урынбасары;

1.3. Бүлек башлыгы;

1.4. Бүлек башлыгы урынбасары;

1.5. Сектор мөдире.

1.6. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль районда Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясе вазыйфасы - министр ярдәмчесе.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «белгечләр» һәм «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

3.1. Финанслау бүлегенең Татарстан Республикасы бюджетын үтәү секторы әйдәүче киңәшчесе

3.2. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторы әйдәүче киңәшчесе

3.3. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторы әйдәүче белгече

3.4. Финанслау бүлегенең федераль бюджетны үтәү секторы 1 разрядлы өлкән белгече

3.5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече

3.6. Аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлегенең әйдәүче консультанты

3.7. Аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлегенең әйдәүче белгече

3.8. Инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлегенең дәүләт заказы секторы әйдәүче белгече

3.9. Аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече

3.10. Азык-төлек базарын үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе

3.11. Игенчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе

3.12. Игенчелек тармакларын үстерү бүлегенең бөртекле һәм техник культуралар секторы әйдәүче киңәшчесе

3.13. Орлыкчылык һәм химияләштерү секторының әйдәүче киңәшчесе

3.14. Терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчес

3.15. Терлекчелек комплексын үстерү секторының әйдәүче киңәшчесе

3.16. Ит җитештерү секторының әйдәүче киңәшчесе

3.17. Сөт җитештерү секторының әйдәүче киңәшчесе

3.18. Икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлегенең әйдәүче киңәшчесе

3.19. Кече хуҗалыкларны үстерү бүлегенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү секторы әйдәүче киңәшчесе

3.20. Кече хуҗалыкларны үстерү бүлегенең әйдәүче белгече

3.21.Кече хуҗалыкларны үстерү бүлегенең әйдәүче консультанты

3.22. Кече хуҗалыкларны үстерү бүлегенең шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерү секторы 1 разрядлы өлкән белгече

3.23. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре бүлегенең әйдәүче киңәшчесе

3.24. Оештыру эше һәм социаль үсеш бүлегенең социаль үсеш секторы әйдәүче белгече

3.25. Техник җиһазлау секторының әйдәүче киңәшчесе

3.26. Терлекчелек һәм энергия ресурслары объектларын механикалаштыру секторының әйдәүче белгече

3.27. Агросәнәгать комплексын инженер-техник тәэмин итү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече.